СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Центральная, дом 35,
поселок Мюд, 423063

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Үзек урам,35 енче йорт
Мюд авылы , 423063

Тел.: (84344) 4-04-33, ОГРН 1061665002508,ОКПО 94318493, ИНН/КПП 1603004864/160301001
E-mail: mud.aks@tatar.ru , http://aksubayevo.tatarstan.ru

# КАРАР

№ 90 16.06.2025 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советына бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы карар кабул итте::

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советына бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга,Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм " Сельская новь"газетасында кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча һәм бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Мюд авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Т.В. Зюзина